ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 01 » июль 2016 ел **№ 727**

**Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибе турында» Башкарма комитетның карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (1 нче кушымта).

1.2. Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеге яисә җир кишәрлекләре схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (2 нче кушымта).

1.3. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (3 нче кушымта).

1.4. Муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль мөлкәтне рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (4 нче кушымта).

1.5. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (5 нче кушымта).

1.6. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (6 нчы кушымта).

1.7. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (7 нче кушымта).

1.8. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (8 нче кушымта).

1.9. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (9 нчы кушымта).

1.10 Җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милеккә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (10 нчы кушымта).

1.11. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында уздырыла торган торгларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (11 нче кушымта).

1.12. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү аукцион рәвешендә уздырыла торган торгларда җир кишәрлеген сату юлы белән милеккә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (12 нче кушымта).

1.13. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (13 нче кушымта).

1.14. Муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (14 нче кушымта).

1.15. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарның һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларының үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен милкенә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (15 нче кушымта).

1.16. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милек буларак (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (16 нчы кушымта).

1.17. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылыкны алып бару өчен гражданнарга милек буларак (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (17 нче кушымта).

1.18. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнарга милек буларак (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (18 нче кушымта).

1.19. Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату

турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (19 нчы кушымта).

1.20. Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (20 нче кушымта).

1.21. Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (21 нче кушымта).

1.22. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (22нче кушымта).

1.23. Милеккә җир кишәрлекләре бирү хокукына ия затлар буларак затларны бушлай исәнкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентын (23нче кушымта).

1.24. Муниципаль милектәге һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (24нче кушымта).

1.25. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең муниципаль милекне арендага бирү буенча административ регламентын (25нче кушымта).

1.26. Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (26 нчы кушымта).

1.27. Әлек хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын(27 нче кушымта).

1.28. Муниципаль милек реестрына керә торган муниципаль мөлкәтне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын(28 нче кушымта).

1.29. Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (29 нчы кушымта).

1.30. Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре әгъзасы булган гражданга җир кишәрлеген түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (30 нчы кушымта).

1.31. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль мөлкәтне биләүгә һәм (яисә) аннан файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (31 нче кушымта).

1.32. Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре милкенә караган җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (32 нче кушымта).

1.33. Муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен торглар үткәрмичә түләүсез файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (33нче кушымта).

1.34. Мондый шартнамә төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча муниципаль милектән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын(34 нче кушымта).

1.35. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милек буларак (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын(35нче кушымта).

1.36. Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (36 нчы кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны О.Е. Спичкинга йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин